ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планын (кушымта итеп бирелә) расларга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 20 ноябре
№ 128-VII ДСП

2025 елның 20 ноябрендәге 128-VII ДСП номерлы
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
Президиумы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чаралары планы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәр | Гамәлгә ашыру буенча чаралар | Үтәү срогы | Башкару өчен җаваплы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Россиядә 2025 ел – Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтү елы. Барлык муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында тантаналы чаралар узды, Ватанны саклаучылар истәлегенә һәйкәлләр, бюстлар һәм мемориаль такталар төзекләндерелде һәм яңалары ачылды.<br>Җиңүнең фронтта да, тылда да нинди зур югалтулар белән ирешелүен без һәрчак истә тотарга тиешбез. Ветераннарның уңайлыклар булдырылган тормышта һәм иминлектә яшәве өчен шартлар тудыру, алар турында кайгырту – барлык дәрәҗә хакимият органнарының бурычы. | 1.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Хәтер һәм искә алу көненә (Бөек Ватан сугышы башлануның 85 еллыгына) багышланган чараларда катнашулары. Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, сугыш елы балалары янына бару һәм аларга ярдәм күрсәтү.<br>1.2. Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен актуаль булган мәсьәләләрне хәл итүдә, аларга адреслы ярдәм һәм булышлык күрсәтүдә ветераннар мәнфәгатьләрендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы иҗтимагый оешмалар, башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек. | ел дәвамында<br><br>ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 2. | Республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларның каһарманлыгын мәңгеләштерү өчен Казан шәһәренең Җиңү паркында һәм муниципаль берәмлекләрдә мемориаль зоналар, шулай ук Татарстан подразделениеләренең Донбассны азат итүдәге өлеше яктыртылган музей экспозициясе төзелә. Бу эшне дәвам итәргә кирәк. | 2.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы эшчәнлеге турында мәгълүмат» мәсьәләсен карау. | 2026 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (А.С. Созинов) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Четерекле вакыйгалар барган чорларда җәмгыятебезнең тагын да ныграк берләшүен күрәбез. Татарстанлылар, йөрәкләре кушканча, хәрбиләребезгә, аларның гаиләләренә, фронтка һәм шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә гуманитар ярдәм күрсәтәләр. Бу мөһим эштә катнашкан һәркемгә олы рәхмәтемне җиткерәм.<br>Гомумән алганда, кешеләргә ихластан булышлык күрсәтү һәм хезмәт итү бүген аеруча зур әһәмият алды. | 2.2. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә гуманитар ярдәм җыю һәм аны җибәрү эшен оештыру, шулай ук Луганск Халык Республикасы һәм Донецк Халык Республикасы халкына спонсор ярдәме күрсәтү. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| | | 2.3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү турында» Татарстан Республикасы законы проектын карау. | 2026 елның мае | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (А.С. Созинов) |
| | | 2.4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү турында» Татарстан Республикасы законы проектын карау. | 2026 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (А.С. Созинов) |
| 3. | Гаиләләренә социаль ярдәм чаралары, шулай ук кайгырту һәм игътибар күрсәтүне тәэмин итеп, Ватанны саклаучыларыбызга ныклы таяныч булдыру – һичшиксез, бик мөһим бурыч.<br>Төрле чорларда Ватанны саклап көрәшкән һәм тылда тырыш хезмәт куйган һәркемгә олы ихтирам йөзеннән 2026 елны Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елы дип игълан итәм. | 3.1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына кирәкле социаль ярдәм һәм булышлык күрсәтү. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| | | 3.2. Татарстан Республикасының индустриаль объектлары эшчәнлеге белән танышу, Татарстан Республикасында сәнәгать үсеше тарихы белән, хезмәт династияләре, шулай ук предприятиеләр эшчеләренең хезмәт шартлары белән танышу. | 2026 елның октябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» депутат төркеме (А.Р. Нәбиева) |
| | | 3.3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына | 2026 елның ноябре | Татарстан Республикасы Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | социаль, психологик һәм белем бирү өлкәләрендә ярдәм чаралары күрсәтү мәсьәләләре буенча Идел буе федераль округы хатын-кыз депутатларының дискуссия мәйданчыклары утырышларын үткәрү. | | Советында «Мәрхәмәт – Милосердие» депутат төркеме (А.Р. Нәбиева) |
| | | 3.4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракциясенең һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ТНВ» депутат төркеменең уртак утырышында «Татарстан Республикасында Хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елын уздыру йомгаклары турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракциясе (Ю.З. Камалтынов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ТНВ» депутат төркеме (А.Р. Габделҗанов) |
| 4. | 14 сентябрьдә Татарстанда бик мөһим иҗтимагый-сәяси вакыйга – Татарстан Республикасы Рәисен һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлау булып узды. Республика сайлаучыларының дүрттән өч өлеше тавыш бирүдә катнашты. Сайлау йомгакларын тулаем Татарстан командасының эшен бәяләү нәтиҗәсе дип саныйм.<br>Гражданнарыбызга – югары активлык күрсәтүләре һәм үзләренең гражданлык позициясен белдерүләре, ә оппонентларга һәм төрле сәяси көчләр вәкилләренә тәкъдимнәре һәм сайлау кампаниясенең эшлекле узуы өчен рәхмәтемне белдерәм. Без республикабыз һәм илебез мәнфәгатьләрендә бергәләп тырыш хезмәт куярга тиешбез. | 4.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ТНВ» депутат төркеменең, «Татарстан – новый век» – «Татарстан – яңа гасыр» республика иҗтимагый хәрәкәте Югары советы әгъзаларының һәм «ТНВ» депутат төркеме әгъзаларының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре вәкиллекле органнарында уртак утырышы.<br><br>4.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында «Тугызынчы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны законнар белән һәм оештыру ягыннан тәэмин итү турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның I кварталы<br><br>2026 елның I кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ТНВ» депутат төркеме (А.Р. Габделҗанов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты (А.Г. Хәбибуллин) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 4.3. Гражданнарны кабул итү:<br>1) сайлау округлары һәм муниципаль районнар, шәһәрләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын беркетү нигезендә;<br>2) Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның Татарстан Республикасында кабул итү бүлмәсендә;<br>3) «ЕДИНАЯ РОССИЯ» партиясе Рәисе Д.А. Медведевның Татарстан Республикасында региональ җәмәгать кабул итү бүлмәсендә;<br>4) КПРФ сәяси партиясенең Татарстан региональ бүлеге кабул итү бүлмәсендә. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 5. | Сайлау кампаниясе барган вакытта республика программаларын һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашырганда исәпкә алынырга тиешле күп кенә тәкъдимнәр бирелде. Парламентның, Хөкүмәт һәм җирле үзидарә органнары яңа составының үзара җайга салынган эшчәнлеге Татарстанның киләчәктә дә тотрыклы үсешен тәэмин итәр дип уйлыйм. | 5.1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын карау. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты<br>(Л.А. Якунин) |
| 6. | Без илебез җитәкчелегенә һәм шәхсән Россия Президенты Владимир Владимирович Путинга җирле үзидарәнең ике баскычтан торган идарә системасын саклаулары өчен рәхмәтле. Авыл территорияләрен үстерүдә моның әһәмияте аеруча зур.<br>Җирле үзидарә органнарында эшләүче кешеләр – кече Ватанны яратуда һәм аның хакына хезмәт итүдә күркәм үрнәк күрсәтүчеләр. | 6.1. «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын әзерләү буенча ведомствоара эшче төркем составында эш.<br><br>6.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан | ел дәвамында<br><br>2026 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты<br>(А.Г. Хәбибуллин)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын карау | | корылышы һәм җирле үзидарә комитеты (А.Г. Хәбибуллин) |
| 7. | Татарстан ислам дөньясы белән, шул исәптән «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме юнәлеше буенча да, өзлексез эш алып баруны дәвам иттерә. Партнерлыкка нигезләнгән (ислам) финанслау чараларына таянып уртак инвестиция проектларын гамәлгә ашыру – хезмәттәшлегебезнең мөһим юнәлешләреннән берсе. Казанда AAOIFI ислам финанслары стандартларын эшләү буенча төп халыкара оешманың беренче вәкиллекле үзәген ачу турында карар кабул ителде, ул Россиядә һәм БДБ илләрендә партнерлыкка нигезләнгән финанслау базарын киләчәктә дә үстерүнең әһәмиятле институты булачак. | 7.1. «Татарстан Республикасы финанс системасына ислам банкингы стандартларын кертү турында» темасына «Хөкүмәт сәгате». | 2026 елның I кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин) |
| | | 7.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Татарстан Республикасы икътисадына партнерлыкка нигезләнгән (ислам) финанслау инструментларын җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| | | 7.3. «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумының «Ислам финанслары һәм инвестицияләре» эшлекле программасы трегында катнашу. | 2026 елның мае | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 8. | Соңгы биш елда республика икътисадында тотрыклы үсеш күзәтелә. Стратегия-2030 да каралган тулай төбәк продуктының күләмен 5 трлн сумга җиткерү бурычы, 2024 ел йомгаклары буенча исәпләгәндә, инде арттырып үтәлде. | 8.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышларында 2025 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисапларны карау. | квартал саен | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин) |
| | | 8.2. «2025 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проектын карау. | 2026 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | (Л.А. Якунин) |
| 9. | Сәнәгатьне үстерүнең нигезен энергетика комплексы тәшкил итә. Республикада 10 ел эчендә 1,7 гигаватт егәрлекле яңа объектлар файдалануга тапшырылды. Шулай ук ТГК-16 Түбән Каманың 1 нче җылылык-электр үзәгенең пар турбиналарын яңартып коруны дәвам иттерә, «ТАНЕКО» АҖ нефть коксын ягу өчен куелган энергетик казан-агрегатларны үзгәртеп коруны төгәлләп килә, «Татэнерго» компаниясе, Түбән Кама җылылык бүлү челтәрләрен алыштырып, зур эш башкарды.<br>Чаллы җылылык-электр үзәген яңартып кору мөһим бурыч булып тора. | 9.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетының уртак утырышында «Татарстан сәнәгатенең конкурентлыкка сәләтлелек факторы буларак энергия нәтиҗәлелеге» мәсьәләсен карау. | 2026 елның сентябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов)<br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 10. | Кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләсе – дәүләт һәм эш бирүчеләр алдында бердәй дәрәҗәдә торган стратегик бурыч.<br>Кадрлар белән тәэмин итү өчен студентларны киләчәктә эшкә урнаштыруны күздә тотып максатчан укырга алу үтемле чара булып тора. Быел компаниянең «Россиядә эш» порталында 4 800 урынга максатчан уку турында шартнамәләр төзү өчен 2 255 тәкъдим бирелгән.<br>Барлык эш бирүчеләрне максатчан укудан файдалануны алдан планлаштырырга һәм шул рәвешчә булачак хезмәткәрләрен җәлеп итәргә чакырам. Моннан тыш, республика Хөкүмәтенә предприятиеләрнең белем бирүнең барлык баскычларында кадрлар әзерләүгә квалификацияле дәүләт биремен формалаштыруда актив катнашуларын тәэмин итүне, әйдәп баручы предприятиеләр базасында студентларга һәм яшь белгечләргә стажировка һәм практика узу өчен программалар комплексын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны, | 10.1. Чаллы шәһәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының күчмә утырышында «Татарстан Республикасында балаларны һәм яшүсмерләрне хезмәт белән тәрбияләү һәм аларга һөнәри юнәлеш бирү турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның июне | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (А.С. Созинов) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | компанияләрдә берләштерелгән уку үзәкләрен һәм яңадан һөнәри әзерлек бирү программаларын булдыруга кызыксындыру тудыруны йөклим. | | | |
| 11. | Эшче кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү инфраструктурасын булдыруда эре бизнесның актив катнашуын билгеләп китәргә кирәк.<br>Без технологик эшкуарлыкка да зур өмет баглыйбыз. | 11.1. Татарстан Республикасында платформалы икътисадның экосистемасын торгызу һәм үстерү буенча Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-парк базасында тематик стратегик сессия. | 2026 елның III кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| 12. | Шулай ук без фундаменталь фәнебезгә ярдәм күрсәтәбез: Татарстанның биш югары уку йорты «Өстенлек-2030» программасында катнаша, грантларны финанслауның гомуми күләме 2 млрд сум тәшкил итә, яшьләрнең «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты кысаларында төзелгән 29 фәнни лабораториясе эшчәнлеге кадрларга кытлыкны бетерүгә юнәлдерелгән. | 12.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2025 елда Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүгә керткән өлеше хакында хисап» мәсьәләсен карау. | 2026 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| 13. | Хөкүмәткә Фәннәр академиясе, югары уку йортлары һәм предприятиеләр белән бергәләп очкычлар, вертолетлар, автомобильләр төзү, радиоэлектроника, яңа материаллар һәм химия, авыл хуҗалыгы, медицина кебек өстенлекле юнәлешләрдә компетенцияләр үзәкләре төзү өчен технологияләр өлкәсендә алдынгылыкка ирешү буенча илкүләм проектларда республиканың актив катнашуын тәэмин итүне, пилотсыз технологияләр, ясалма фәһем һәм биотехнологияләрне дә кертеп, фәнара яңа | 13.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хисабы» мәсьәләсен карау.<br><br>13.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек | 2026 елның марты<br><br>2026 елның сентябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов)<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тикшеренү юнәлешләрен булдыруны һәм эшләтүне, шулай ук бу фәннәрне белем бирү программаларының барлык баскычларына кертү мәсьәләсен эшләүне йөклим. | сәясәте комитеты утырышында «Агросәнәгать комплексында кадрлар» федераль проектын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | | табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты<br>(А.К. Хамаев) |
| 14. | Кадрларга кытлык шартларында хезмәт җитештерүчәнлеген яхшырту төп бурыч булып тора. Бу юнәлештәге федераль һәм республика проектларында һәм ярдәм чараларында мөмкин булганча күбрәк катнашырга, сәнәгать предприятиеләрендә ясалма фәһем һәм робот техникасы элементларын файдалана башларга кирәк. | 14.1. «Иннополис» махсус икътисадый зонасы технопаркында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының күчмә утырышында «Җитештерү процессларына илебезнең цифрлы чишелешләрен гамәлгә кертү турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның июне | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты<br>(Р.Г. Хөсәенов) |
| | | 14.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракциясе утырышында «Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүдә ярдәм» илкүләм проектын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның октябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракциясе<br>(Ю.З. Камалтынов) |
| 15. | Үсешкә этәргеч бирә торган яңа ноктлар табып, бизнес өчен инфраструктураны үстерү эшен, шулай ук инвестиция проектларын һәм Инвестиция мохитен яхшырту планы чараларын гамәлгә ашырганда хакимиятнең барлык дәрәҗәләре, предприятиеләр һәм ресурслар белән тәэмин итү оешмаларының үзара килешенгән эшчәнлеген оештыруны дәвам иттерергә кирәк.<br>ИТ-өлкәгә инвестицияләр җәлеп итүне дәвам итәргә кирәк. | 15.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында «Татарстан Республикасы предприятиеләре соравы буенча инвестицион җәлеп итүчәнлек факторы буларак ИТ-тармак өчен квалификацияле кадрлар әзерләү» мәсьәләсен карау. | 2026 елның июле | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты<br>(Р.Г. Хөсәенов) |
| 16. | Кече һәм урта бизнес республикабызның социаль-икътисадый үсешендә мөһим урын | 16.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракциясе | 2026 елның апреле | Татарстан Республикасы Дәүләт |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тота.<br>Яңа эш башларга нияте булган кешеләргә үз проектларын тормышка ашыруда ярдәм итү, авыл халкының хезмәт активлыгын арттыру, шулай ук авыл хуҗалыгы кооперацияләрен алга таба да үстерү эшен дәвам иттерү зарур. Кооперативларга булышу чарасы буларак ел саен 200 млн сум акча бүлеп бирү турында карар кабул ителде. | утырышында «Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгында кече һәм урта бизнесны үстерү турында»гы мәсьәләне карау. | | Советында «ЕДИНАЯ РОССИЯ» фракциясе (Ю.З. Камалтынов) |
| 17. | Азык-төлек өлкәсендә куркынычсызлыкны тәэмин итү өстенлекле бурыч булып тора.<br>Республика авыл хуҗалыгы продукциясенең барлык төрләре белән тулысынча тәэмин ителгән. Бу, беренче чиратта, безнең авыл хезмәтчәннәренең тырыш хезмәте нәтиҗәсе, моның өчен аларга ихлас рәхмәт сүзләремне белдерәм! | 17.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышларында «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәү турында»гы мәсьәләне карау.<br><br>17.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең һәм эшкәртүнең инновацион технологияләрен гамәлгә кертү турында»гы мәсьәләне карау. | квартал саен<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2026 елның ноябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты (А.К. Хамаев)<br><br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты (А.К. Хамаев) |
| 18. | Шәхси хуҗалыклар дистәләгән мең гаиләләрнең керем чыганагы, авылларның нигезе булып тора. Быел аларга ярдәм йөзеннән республика бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаның күләмен 700 млн сумга җиткердек. | 18.1. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының берсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Бюджет, салымнар һәм финанс комитетының күчмә утырышында «Шәхси хуҗалыкларга һәм | 2026 елның июне-июле | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Республикада нык хуҗалыклар нигезләгән булдыклы җитәкчеләрнең тулы бер сыйныфы оешты.<br>Сезгә һәм республикабызның барлык фермерларына хезмәтегез өчен рәхмәтемне белдерәм.<br>Шулай ук барлык шәһәр халкы исеменнән авыл хезмәтчәннәренә ярминкәләр уздырулары, безне югары сыйфатлы, экологик чиста продуктлар белән тәэмин итүләре өчен ихлас рәхмәт сүзләре җиткерәм. | авыл хуҗалыгы кооперацияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс ярдәме турында»гы мәсьәләне карау. | | (Л.А. Якунин) |
| 19. | Икътисадның тотрыклы үсеше, шулай ук федераль үзәкнең ярдәме нәтиҗәсендә бөтен республикада илкүләм проектларны һәм республика программаларын тормышка ашыру дәвам иттерелә, аларның төп максаты – гражданнарның тормышын яхшырту. | 19.1. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән берлектә илкүләм проектларны җирле дәрәҗәдә локальләштерү буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән дискуссияләр сериясе. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты (Р.Г. Хөсәенов) |
| | | 19.2. Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын һәм аларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрне карау (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары карамагындагы мәсьәләләр өлешендә). | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 20. | Соңгы биш елда зур эшләр башкарылды: 540 млрд сумга 22 меңнән артык социаль объект төзелде һәм капиталь төзекләндерелде, 15 млн кв. метр торак тапшырылды. Файдалануга тапшырылган торакның күләме инде дүртенче ел рәттән 3 млн кв. метрдан артып китә, 600 меңнән артык гаилә үзенең торак шартларын яхшыртуга иреште.<br>Әлеге саннарда Президентыбыз Владимир Владимирович Путинның өлеше гаять зур, аның | 20.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Татарстан Республикасында торак төзелеше өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның I кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | йөкләмәләре нигезендә гаиләләргә, авыл халкына булышуга юнәлтелгән ипотекалар, ИТ-ипотека һәм башка төрле бик күп ярдәм чаралары гамәлгә ашырыла.<br>Моннан тыш, республиканың социаль ипотека программасы кысаларында табиблар, укытучылар, предприятие хезмәткәрләре һәм бюджетның башка тармакларында эшләүче 12 меңнән артык гаилә фатир ачкычлары алды, күпфатирлы йортларда өлешле төзелештә катнашучылар белән бәйле четерекле мәсьәләләр тулысынча хәл ителде – 3 меңнән артык кешенең милеккә хокукы торгызылды. | | | |
| 21. | Биш ел эчендә «Безнең ишегалды» программасы кысаларында бөтен республика буенча 1,5 млн кеше яши торган 5 174 күпфатирлы йорт ишегалды төзекләндерелде, гомуми суммасы 54 млрд сумга төште. Ял итү, аралашу, балалар тәрбияләү өчен заманча һәм куркынычсыз мәйданчыклар булдырылды. Яңартылган ишегаллары яше-картының яраткан урынына әйләнде.<br>10 ел эчендә җәмәгать урыннарын үстерү дәүләт программасы кысаларында барлык 45 муниципалитетта гомуми суммасы 33 млрд сумга 450 парк, сквер, бульвар һәм яр буйлары төзекләндерелде.<br>Кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән республика программалары алга таба да дәвам иттереләчәк. | 21.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Татарстан Республикасында җәмәгать урыннарын төзекләндерү программаларын («Безнең ишегалды», «Яшәү өчен уңайлы мохит булдыру») гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның III кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 22. | Торак-коммуналь инфраструктура объектларын яңарту республика программасын эшләтеп җибәрү киләсе биш елга алда торган иң җитди һәм зур чыгымнар сорый торган бурычларның | 22.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «2023 – 2027 елларга Татарстан | 2026 елның IV кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | берсе булып тора. Әлеге өлкә республикада яшәүче һәр кешегә дә кагыла. Быел коммуналь челтәрләрне төзүгә һәм яңартуга 16 млрд сум акча бүлеп биреләчәк. Безнең бурыч – челтәрләрдә өзеклекләр булдырмау максатында алдан төзекләндерү эшләре алып бару, аварияләр санын һәм коммуналь челтәрләрдә югалтуларны бермә-бер киметү. | Республикасында коммуналь инфраструктураны модернизацияләү региональ программасын гамәлгә ашыру барышы турында»гы мәсьәләне карау. | | инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 23. | Быел тагын 1,5 мең километр юл төзеләчәк һәм төзекләндереләчәк, Чаллы шәһәреннән Башкортостан чигенә кадәр М-7 автомобиль юлында реконструкцияләү эшләре алып барыла, шулай ук Сокуры поселогына кермичә әйләнеп уза торган юл төзелә. Илебез Хөкүмәте булышлыгы белән Оренбург трактының тиңдәше булган ярдәмче юл төзү турында карар кабул ителде. Шулай ук урамнардагы юллар челтәрен төзекләндерү дә аерым игътибарга алыначак. Әлеге максатларга 35 млрд сум акча бүлеп биреләчәк. | 23.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Татарстан Республикасында юл-транспорт комплексын үстерү турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |
| 24. | Елга транспорты буенча – бүгенге көндә су транспортында йөк ташу җитәрлек күләмдә түгел (33 млн тонна).<br>Җир өсте транспортын үстерү кысаларында Россия Президенты Владимир Владимирович Путин йөкләмәсе нигезендә 2030 елга шәһәр транспортының 85 процентын норматив срогыннан да артыграк куллану тыелачак. Соңгы биш елда республикада 463 яңа автобус һәм 72 троллейбус сатып алынды. Җәмәгать транспортының нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәргә, шулай ук авыл җирлекләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә ярдәм чараларын эшләргә кирәк. Моннан тыш, метро станцияләре һәм җәмәгать транспортының башка төрләренә | 24.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында «Пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнарын мониторинглау турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның III кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты (А.Ю. Егоров) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күчеп утыру мөмкинлеген булдыру максатында тукталышлар янында шәхси транспорт кую урыннарын оештыру мәсьәләсен карап тикшерү зарур. | | | |
| 25. | Мәгариф өлкәсе – безнең киләчәгебезнең нигезе. Тулаем алганда, укытучы һөнәренең абруен һәм дәрәҗәсен күтәрү юнәлешендә эшне дәвам итәргә кирәк. | 25.1. «Мәгариф өлкәсендәге проблемалар» темасына түгәрәк өстәл уздыру. | 2026 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе (Х.Г. Миргалимов) |
| | | 25.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татарстан Республикасында белем бирү оешмаларын кадрлар белән тәэмин итү турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| 26. | Без «Физика-математика алгарышы» проектына зур өметләр баглыйбыз. Аны гамәлгә ашыруга республика бюджетыннан ел саен 250 млн сумнан артык акча бүлеп биреләчәк. Әлеге проектның нигезенә салынган барлык караш-алымнарны башка табигать фәннәрендә дә, беренче чиратта химия фәнендә, киңрәк файдалану мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. | 26.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Физика-математика алгарышы» проектын гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның сентябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| 27. | Республикада сабыйларны яклау, балаларга һәм яшүсмерләргә ярдәм күрсәтүне арттыру, алар өчен бертигез мөмкинлекләр булдыру мәсьәләләрен хәл итүгә зур игътибар бирелә.<br>Россия Президенты Владимир Владимирович Путин йөкләмәсе нигезендә булдырылган «Алдынгылар хәрәкәте» балалар һәм яшьләр бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте кысаларында актив эш алып барыла. Бүгенге көндә ул 300 меңгә якын баланы һәм остазны | 27.1. «Татарстан патриотлары» темасына түгәрәк өстәл уздыру («Алдынгылар хәрәкәте» балалар һәм яшьләр бөтенроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең Татарстан Республикасы региональ бүлеге эшчәнлеге мисалында). | 2026 елның мае | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (А.С. Созинов) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | берләштерә.<br>Яшьләрнең барлык категорияләре белән системалы һәм комплекслы эш алып баруны дәвам итәргә, патриотик тәрбия бирүгә аеруча зур игътибар бирергә кирәк. Бу – илебез иминлеге, традицион рухи-әхлакый хәзинәләребезне һәм буыннар арасында бәйләнешне саклау мәсьәләсе. | | | |
| 28. | Кешеләрнең сәламәтлеге һәр җәмгыятьнең нигезен тәшкил итә. | 28.1. «Сәламәтлек саклау өлкәсендәге проблемалар турында» темасына түгәрәк өстәл уздыру. | 2025 елның ноябре – 2026 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында КПРФ фракциясе (Х.Г. Миргалимов) |
| | | 28.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында «2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планын) гамәлгә ашыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның ноябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты (А.С. Созинов) |
| 29. | Авыруларны кисәтү чараларына да зур игътибар бирелә. Узган биш елда диспансеризация узучыларның саны биш тапкырга артты һәм алар 1,5 млн кеше тәшкил итте. «Сәнәгать диспансеризациясе» кысаларында эшләүче 300 меңнән артык граждан эш урыннарында килеш үзләренең сәламәтлеген тикшерә алды. | 29.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты утырышларында 2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы хисапларны карау. | квартал саен | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин) |
| | | 29.2. «2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проектын карау. | 2026 елның II кварталы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты (Л.А. Якунин) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 30. | Татарстанда халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең шәхси ихтыяҗларны күздә тоткан, һәркем файдалана ала торган һәм чын мәгънәсендә нәтиҗәле булган чаралары гамәлгә ашырыла. Соңгы елларда без балалы гаиләләргә, олы яшьтәге гражданнарга, инвалидларга һәм төрле ихтыяҗлары булган башка затларга ярдәм күрсәтү ысулларын шактый киңәйтүгә ирештек. Олы яшьтәге кешеләрне һәм инвалидларны озак вакытка тәрбиягә алу системасына аеруча зур игътибар бирелә. Зеленодольск шәһәрендә «Тәрбия йорты»н төзү мөһим проект булып тора. Бу юнәлештә даими контроль булырга тиеш. | 30.1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары эшчәнлегендә катнашуы турында» 2025 елның 13 февралендәге 33-VII ДСП номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары нигезендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары эшчәнлегендә катнашу. | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары |
| 31. | Киләсе елда бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел, Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 120 ел була. Аларның иҗаты бүген дә тормышчан. Безнең уртак бурыч – шагыйрьләрнең мирасын киң таныту. | 31.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында «Муса Җәлилнең тууына 120 ел тулу уңаеннан бәйрәмгә әзерлек һәм аны уздыру турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның феврале | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| | | 31.2. «Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулу уңаеннан бәйрәмгә әзерлек һәм аны уздыру турында» темасына «Хөкүмәт сәгате». | 2026 елның марты | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты (А.Р. Зарипов) |
| 32. | Гомумән алганда, татар халкының милли тәңгәллеген саклау, шул исәптән цифрлы мохиттә дә, аның милли кодын таныту буенча киләчәктә дә бергәләп тырышлык куярга кирәк. Республика Хөкүмәтенә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән | 32.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында «Татар халкының милли үзенчәлеген саклап калу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы | 2026 елның ноябре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | берлектә Татар халкының милли тәңгәллеген саклау программасына, аны танытуга тагын да зуррак игътибар биреп, тиешле үзгәрешләр кертүне йөклим. | турында»гы мәсьәләне карау. | | (А.Р. Зарипов) |
| 33. | | 33.1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан региональ бүлеге эшчәнлеге турында»гы мәсьәләне карау. | 2026 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты (А.А. Чубаров) |